ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.05.2023 ел Баулы шәһәре № 119

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районында спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында» 2020 елның 20 маендагы 113 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (2020 елның 28 маендагы 120 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 241 номерлы, 2022 елның 30 декабрендәге 281 номерлы карарлары)

2022 елның 26 маендагы 489 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Татарстан Республикасында спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү шартлары турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында», «Татарстан Республикасында спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура- спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында” һәм 2022 елның 30 ноябрендәге 1268 номерлы “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында «Татарстан Республикасында спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында» карарларына ярашлы Татарстан Республикасы

Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

Карар итә:

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 20 маендагы 113 номерлы «Баулы муниципаль районында спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында» (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 маендагы 120 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 241 номерлы, 2022 елның 30 декабрендәге 281 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

Баулы муниципаль районында спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында Нигезләмәдә (күрсәтелгән карарга 1 нче кушымта):

IV «Спорт резервы әзерләү оешмалары хезмәткәрләре тарафыннан база хезмәт хакының бер сәгатенә (хезмәт хакының база ставкасына) күрсәтелә торган хезмәтләрнең норматив саны» бүлегендә:

1 нче таблицаны 87-88 пунктлары белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «87 | Су асты спорты | 1,50 | 2,80 | 3,70 | 6,70 | 6,70 | 8,90 | 8,90 | 10,00 | 17,0 | 23,0 | 35,0 |
| 88 | Флорбол | 1,5 | 2,2 | 3,2 | 5,6 | 5,6 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 17,0 | 20,0 | 25,0»; |

2 нче таблицаны 87-88 пунктлары белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «87 | Су асты спорты | 4 | 6 | 8 | 12 | 12 | 16 | 16 | 18 | 24 | 24 | 32 |
| 88 | Флорбол | 4 | 6 | 8 | 12 | 12 | 18 | 18 | 18 | 20 | 22 | 24»; |

3 нче таблицаны 87-88 пунктлары белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «87 | Су асты | 15 | 12 | 12 | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 | 4 | 4 | 2 |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | спорты | | | | | | | | | | | |
| 88 | Флорбол | 15 | 15 | 14 | 12 | 12 | 10 | 10 | 10 | 6 | 5 | 3»; |

7 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 таблица

Тренер, тренер-укытучыларның адаптив физик культура буенча (шул исәптән өлкәннәр) бер укучы өчен, ярышларда алган урыны буенча, югары квалификацияле спортчыларны әзерләгәне өчен хезмәт хакы нормативлары

(процентлар)

| Ярышлар дәрәҗәсе | Алган урын | Хезмәт хакы түләү нормативлары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | олимпия, паралимпия, сурдлимпия спорт төрләре; олимпия, паралимпия, сурдлимпия дисциплиналары | | неолимпия спорт төрләре, неолимпия дисциплиналары; непаралимпия, несурдлимпия дисциплиналары | |
| | | шәхси | командалы | шәхси | командалы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Олимпия уеннары, Паралимпия уеннары, Сурдлимпия уеннары | 1 | 500,0 | 500,0 | - | - |
| | 2 | 375,0 | 375,0 | - | - |
| | 3 | 250,0 | 250,0 | - | - |
| | 4 | 200,0 | 200,0 | - | - |
| | 5 | 188,0 | 188,0 | - | - |
| | 6 | 125,0 | 125,0 | - | - |
| | катнашу | 63,0 | 63,0 | - | - |
| Дөнья чемпионаты | 1 | 75,0 | 75,0 | 52,5 | 37,5 |
| | 2 | 70,0 | 70,0 | 50,0 | 35,0 |
| | 3 | 65,0 | 65,0 | 47,5 | 32,5 |
| | 4 | 60,0 | 60,0 | 45,0 | 30,0 |
| | 5 | 55,0 | 55,0 | 42,5 | 27,5 |
| | 6 | 50,0 | 50,0 | 35,0 | 25,0 |
| | 1 | 70,0 | 70,0 | 50,0 | 35,0 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Дөнья Кубогы, Европа чемпионаты | 2 | 65,0 | 65,0 | 45,0 | 32,5 |
| | 3 | 60,0 | 60,0 | 42,5 | 30,0 |
| | 4 | 55,0 | 55,0 | 37,5 | 27,5 |
| | 5 | 50,0 | 50,0 | 35,0 | 25,0 |
| | 6 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 7 - 12 | 15,0 | 15,0 | 12,5 | 7,5 |
| Ир-атлар һәм хатын-кызлар арасында рәсми халыкара ярышлар | 1 | 20,0 | 20,0 | 10,0 | 10,0 |
| | 2 | 17,5 | 17,5 | 8,8 | 8,8 |
| | 3 | 15,0 | 15,0 | 2,5 | 7,5 |
| Европа Кубогы | 1 | 60,0 | 60,0 | 42,5 | 30,0 |
| | 2 | 55,0 | 55,0 | 37,5 | 27,5 |
| | 3 | 50,0 | 50,0 | 35,0 | 25,0 |
| | 4 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 5 - 10 | 22,5 | 22,5 | 20,0 | 11,3 |
| Бөтендөнья универсиадасы | 1 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 2 | 40,0 | 40,0 | 27,5 | 20,0 |
| | 3 | 35,0 | 35,0 | 22,5 | 17,5 |
| | 4 - 6 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 10,0 |
| Россия чемпионаты | 1 | 50,0 | 17,5 | 35,0 | 8,8 |
| | 2 | 45,0 | 15,0 | 32,5 | 7,5 |
| | 3 | 40,0 | 12,5 | 27,5 | 6,3 |
| | 4 | 35,0 | 10,0 | 25,0 | 5,0 |
| Россия Кубогы | 1 | 40,0 | 15,0 | 27,5 | 7,5 |
| | 2 | 35,0 | 12,5 | 22,5 | 6,3 |
| | 3 | 30,0 | 10,0 | 20,0 | 5,0 |
| | 4 | 25,0 | 8,5 | - | 4,3 |
| Федераль округ чемпионаты | 1 | 25,0 | 7,5 | 22,5 | 3,8 |
| | 2 | 20,0 | 7,0 | 18,0 | 3,5 |
| Татарстан | 1 | 10,0 | 3,5 | 5,0 | 1,8 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Республикасы чемпионаты | | | | | |
| Россия беренчелеге (яшьләр, юниорлар) | 1 | 35,0 | 7,3 | 30,0 | 3,7 |
| | 2 | 30,0 | 6,8 | 25,0 | 3,4 |
| | 3 | 25,0 | 6,3 | 22,5 | 3,2 |
| | 4 | 20,0 | 5,8 | 20,0 | 2,9 |
| Бөтенроссия универсиадасы | 1 | 35,0 | 7,3 | 30,0 | 3,7 |
| | 2 | 30,0 | 6,8 | 25,0 | 3,4 |
| | 3 | 25,0 | 6,3 | 22,5 | 3,2 |
| | 4 | 20,0 | 5,8 | 20,0 | 2,9 |
| Европа, дөнья беренчелеге | 1 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 2 | 40,0 | 40,0 | 27,5 | 20,0 |
| | 3 | 35,0 | 35,0 | 22,5 | 17,5 |
| | 4 - 6 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 10,0 |
| Бөтендөнья яшүсмерләр уеннары | 1 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 2 | 40,0 | 40,0 | 27,5 | 20,0 |
| | 3 | 35,0 | 35,0 | 22,5 | 17,5 |
| | 4 - 6 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 10,0 |
| Европа яшүсмерләр фестивале | 1 | 40,0 | 40,0 | 20,0 | 20,0 |
| | 2 | 35,0 | 35,0 | 17,5 | 17,5 |
| | 3 | 30,0 | 30,0 | 15,0 | 15,0 |
| | 4 - 6 | 20,0 | 20,0 | 10,0 | 10,0 |
| Юниорлар, егетләр, кызлар, малайлар, кызлар арасында рәсми халыкара ярышлар | 1 | 22,5 | 15,0 | 15,0 | 15,0 |
| | 2 | 20,0 | 12,5 | 12,5 | 12,5 |
| | 3 | 17,5 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| | 4 | 15,0 | 7,5 | 7,5 | 7,5 |
| Россия беренчелеге (егетләр, кызлар, малайлар, кызлар) | 1 | 35,0 | 6,0 | 18,0 | 3,0 |
| | 2 | 28,0 | 5,5 | 14,0 | 2,7 |
| | 3 | 20,0 | 5,0 | 10,0 | 2,5 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Россия яшьләре Спартакиадасы финалы | 1 | 37,5 | 7,5 | 32,5 | 3,8 |
| | 2 | 32,5 | 7,0 | 27,5 | 3,5 |
| | 3 | 27,5 | 6,5 | 22,5 | 3,3 |
| | 4 - 6 | 25,0 | 6,0 | 20,0 | 3,0 |
| Россия укучылары Спартакиадасы финалы | 1 | 37,5 | 7,5 | 32,5 | 3,8 |
| | 2 | 30,0 | 7,0 | 25,0 | 3,5 |
| | 3 | 27,5 | 6,5 | 22,5 | 3,3 |
| | 4 - 6 | 22,5 | 6,0 | 18,0 | 3,0 |
| Россия Федерациясе спорт Министрлыгының бердәм календарь планына кертелгән Бөтенроссия ярышлары | 1 | 15,0 | 5,0 | 7,5 | 2,5 |
| | 2 | 12,5 | 2,5 | 6,8 | 1,3 |
| | 3 | 10,0 | 2,0 | 5,0 | 0,8 |
| Идел буе федераль округы беренчелеге | 1 | 20,0 | 5,8 | 10,0 | 2,9 |
| | 2 | 17,5 | 5,3 | 9,0 | 2,7 |
| | 3 | 15,0 | 4,8 | 7,5 | 2,4 |
| Олимпия резервы дәүләт училищесына укырга керү | - | 25,0 | 25,0 | - | -»; |

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Спортның аерым төрләрендә, төп тренердан тыш, спортчылар белән бер үк вакытта эшләү шарты белән, спортның якын төрләре (акробатика, хореография һ.б.) буенча булган тренерлар да җәлеп ителергә мөмкин. Аларның хезмәт хакы, төп тренерларның хезмәт хакы нормативлары буенча, әлеге Нигезләмәнең 1 таблицасы буенча эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла, әмма ул төп тренер өчен каралган хезмәт хакы нормативының яртысыннан артмаска тиеш.»;

VII «Компенсация характерындагы түләүләр» бүлегенең 4 пунктының алтынчы абзацында «3,5» саннарын «20,0» саннары белән алыштырырга;

гомуми тармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре, җитәкчеләрнең

гомуми тармак вазифалары, Баулы муниципаль районында спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмалары белгечләре һәм хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында Нигезләмәдә (күрсәтелгән карарга 2 нче номерлы кушымта):

IV «Стимуллаштыручы характердагы түләүләр» бүлегендә:

2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр.»;

түбәндәге эчтәлектәге 6 нчы пункт белән тулыландырырга:

«6. Хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр, эшчеләрнең гомуми тармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре, җитәкчеләрнең гомуми тармак вазифалары, Баулы муниципаль районында спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмалары белгечләре һәм хезмәткәрләренә билгеләнә, һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{it} = O_d \times D_{it},$$

анда:

$B_{it}$ - хезмәт интенсивлыгы өчен түләү

$O_d$ - эшчеләрнең гомуми тармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре, җитәкчеләрнең гомуми тармак вазифалары, Баулы районында спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмалары белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазифа оклады;

$D_{it}$ - хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә күләм.

Размеры надбавок за интенсивность труда приведены в таблице 2 приложения к настоящему Положению.».

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмәләр күләме әлеге Нигезләмә кушымтасының 2 нче таблицасында китерелә.».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән

хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров